Мөслим

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

МБМББУ «Ләйсән»

# «Ләйсән»
# балалар бакчасының
# үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге

# 1987-2016 нче еллар



Газизова Зәнфирә Җәләлетдин кызы 1947 нче елның 5 нче гыйнварында Мөслим районында туган. 1987-2002 нче еллардан Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында мөдир булып эшләгән. 42 ел педагогик стажы булган, ”Мәгариф отличнигы, хәзерге көндә лаеклы ялдагы Зәнфирә Җәләлетдин кызының истәлекләренән. ”Ләйсән” балалар бакчасы 1987 нче елның 1 нче сентябреннән төзелә башлады, 1988 нче елның 1 январеннан балалар кабул итә башладык .Төзелешне Бөгелмә шәһәренең УСЗМ оешмасы , нефть кудыру станциясе башкарды. Бакча хезмәткәрләре көче белән ишегалды тигезләнде, уен мәйданчыклары ясалды, агачлар, куаклар утыртылды. Мәйданчыкларга 3 гөмбә (беседка) урнаштырылды, аның стеналарына мозайкадан төрле әкиятләрдән рәсемнәр ябыштырып ясалды. Яшелчә, җиләк –җимеш бакчасы булдырылды, аннан алынган уңыш тәрбияләнүче балаларга туклануга тотылды.

Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасы ул чор өчен заманча җиһазландырылган, барлык уңайлыклары булган райондагы иң яхшы балалар бакчасы булып торды. Төркемнәрдә 32 шәр бала белем һәм тәрбия алды. Бакчада тәрбияләнеп чыгып киткән балалар мәктәпләрдә бик яхшы билеләргә укып, безне сөендерделәр.


Районара, республика күләм конкурсларда катнашып, коллектив зур уңышларга иреште. Тәрбиячеләрнең хезмәтләре дә югары бәяләнде. ”Мәгариф отличнигы”, ”Мәгарифтәге казанышлары өчен” билгеләре белән бүләкләнделәр. Бакчада алып барылган тәрбияви эшләр район гәзитендә яктыртылып барылды.

1995 нче елдан бакчабыз район мәгариф бүлеге карамагына күчерелде.




экологическое воспитание
экологическая тропа













# 2016-2020 нче ел

2016 нчы елдан бакчаны Мөхәмәтова Резеда Рәшит кызы җитәкли. “Ләйсән” балалар бакчасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем һәм тәрбия бирүче, 32 еллык тәҗрибәсе булган балалар бакчасының берсе булып тора. 2017 нче елда Федераль дәүләт белем бирү программаларына кертелеп “Ләйсән” балалар бакчасына капиталь ремонт үткәрелде. Бакча терреториясе яңа коймалар белән әйләндерелеп алынды, җире тигезләнеп газон чәчелде, асфальт җәелде, туя агачлары утыртылды, мафлар куелды. Төркемнәрнең ял итү урыннары, гөмбәчекләр яңартылып,буялды, бакча бинасы җылытылды.тышланды,яңа утлар эленде. Эчке якта 4 төркем, уен, юыну, чишенү бүлмәләре, шәфкать туташы, мөдир, методик бүлмә, кер юу бүлмәләре заман таләпләренә туры китерелеп ремонтланды һәм җиһазландырылды. Икенче катта яңа ике бүлмә ясалды. Юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү бүлмәсендә методик ярдәмлекләр, дидактик материаллар тупланды. Балаларга юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү буенча еллык план төзелде. Экологик тәрбия бирү максатыннан, Кышкы бакча булдырылды, гөлләр утыртылды. Бакчабыз яңа сулыш белән кабаттан эшли башлады. Хәзерге көндә Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында 23 хезмәткәр эшли. 4 төркемдәге 105 балага югары белемле 8 тәрбияче, 1 музыкант белем һәм тәрбия бирәләр. Бакчада тәрбия һәм белем бирү процессы куелган таләпләргә, расланган документларга нигезләнеп режим буенча алып башкарыла. Балаларның туклануы 4 тапкыр бердәм төзелгән менюга нигезләнеп оештырыла. Бакчабызның төп максаты: яңа технологияләргә таянып, белемгә омтылучан мөстәкыйль, физик һәм сәламәт, сәләтле балалар тәрбияләү.











# 2020 - …









# 2020 - …





